Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

23 март, 2021 ел № 9

«2016-2020 елларга Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 15 мартындагы 3 номерлы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Күн авыл җирлеге Уставы нигезендә Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге башкарма комитеты карар кабул итте:

1. Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 15 мартындагы 3 номерлы карары белән расланган «2016-2020 елларга Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021-2023 елларга Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасы (алга таба - муниципаль Программа);

2. Әлеге карарны Күн авыл җирлегенең Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Баһауов